ISSN 0136—7110

Чаян



1923 елның январеннан чыга

5

Март * 1984 * Казан

Е. ХИТРОВА рәсеме.



Карышуның мәгънәсе юк

Әле генә буялган, балкып торган бер пароход причалдан кузгалып китеп бераз барган да борылган, ди, имеш. Шулчак ярдагылар аның теге як бортын күреп шаккатканнар: борт бөтенләй буялмаган килеш икән.

— Алдакчылар! Акчаны тулысынча алдыгыз, ә судноны бер генә яктан буягансыз!— дип озын берлекчеләр бригадасына ябырылган пароходчылык хезмәткәрләре.

— Нишләп алдакчы булыйк?— дигән озын берлекчеләр.— Килешенү язуы нигезендә без, бер яктан, корабльне буяуны өстебезгә алдык, сез, икенче яктан, түләүне...

Кукмара киез итек фабрикасының киез цехы производство начальнигы Р. Фәтхерахмановка килгәндә, ул да шушы мәзәктәгедәй хәлгә юлыкты. Шунысы гына бар, алар шикелле итеп аклана гына алмый ул. Чөнки ул килешенү йөкләмәсен ике яктан да үз өстенә алды.

1983 елның 27 июнендә төзелгән хезмәт килешенүендә Р. Фәтхерахманов, бер яктан, заказчы буларак, В. Аввакумов бригадасына 12396 сум да бер тиен акча түләүне үз өстенә ала. Икенче яктан, шул ук Р. Фәтхерахманов киптергеч һәм киез тапап җәйгеч машинаны аяк киеме киезләре цехына алып керүдә, аны шунда җыюда һәм эшләтә башлауда бригадага ярдәм итәргә алына.

Бу яңа җайланмага урын бушату өчен бригада шул ук Фәтхерахмановның ярдәме белән элеккеге җиде машинаны һәм агрегатны моннан сүтеп алып, яңа урынга илтеп, корып куярга тиеш була.

Шулай итеп, заказ дигәнеңне заказчы үзе үтәргә тотына. Производство начальнигы Р. Фәтхерахманов үзе, ягъни мәсәлән.

Бер караганда, Аввакумов белән Фәтхерахманов арасындагы хезмәт бәйләнешләре тәмам чуалып бетәргә тиеш иде кебек. Ялланган бригаданың бригадиры производство начальнигына буйсынырга тиеш ләбаса! Шул ук вакытта производство начальнигы бригадир өчен начальник та түгел кебек. Чөнки бригадир җитәкләгән бригадада эшләүче гади эшче генә бит ул...

Юк, чуалыш-буталышлар булмады. Аввакумов хезмәт килешенүендә генә башлык булып исәпләнде.

Җиде кешелек бригада җир җимертеп эшләде. Беркем дә шәхси вакыты белән исәпләшеп тормады. Р. Фәтхерахманов исә үзенең чираттагы ялын да кызганмады. Ә нигә эшләмәскә? Мондый акчаны котып тирәләрендә дә түләмиләрдер, валлаһи! Эшләнгән эш күләмен дә үзең теләгәнчә күрсәтергә була.

Җиде машинаны һәм агрегатны сүтеп, аларга капиталь ремонтны ясаган һәм монтажлаган өчен, бригада 10 мең сум тирәсе акча алды. Капиталь ремонт ясауның кирәге дә юк иде, югыйсә. Техника яңа иде әле.

Мисал өчен, ватрама дигән җайланманы сүтеп-җыйганы һәм капиталь ремонт ясаганы өчен, бригада 600 сум алды. Ә чынлыкта исә ул ватраманы алар сүтелмәгән килеш бер читкә этәрделәр дә, киптергеч һәм киез тапап җәйгеч машинаны монтажлаганнан соң, үз урынына утыртып куйдылар.



Эшләнгән эшләр турында бер як төзегән наряд буенча икенче як (контрольлек итүче як) һич карусыз акча түләде. Нигә карышып торырга? Контрольлек итүче як дигәне бөтенләй булмады да бит! Әйтик, производство начальнигының карусызлыгы аңлашыла — карышып маташу аның файдасына түгел. Дөрес, хезмәт һәм хезмәткә түләү бүлеге (ОТиЗ)дә бар монда. Инде дә килеп, директор үзе дә бар. Әмма дә ләкин нишләп әле ОТиЗ начальнигы А. Аввакумова бригада башлыгына — газиз ире В. Аввакумовка каршы килеп торсын ди инде, булмаганны! Фабрика директоры К. Бариев та акча документларына бик рәхәтләнеп «Түләргә!» дип кул куйды. Үзенең кияве — техник бүлек конструкторы Ш. Әхмәтшин — җиң сызганып эшләп йөргән бригадага ничек ышанмасын инде ул?!

Әйе, мондый хәлләрдә пароходның бер ягы гына буялганын күрми калуың да гаҗәп түгел шул.

П. ШАҺРАЙ,
«Чаян»ның махсус корреспонденты.

И. ХАНТИМЕРОВ рәсеме.



— Сиңа тунлык сәмән юк, дип шыңшып тормаган бу ир, ичмасам!



Безгә ишетелгәнчә, Әлмәт автобусларының кайбер шоферлары пассажирларны ерып чыккысыз авыр хәлләрдә калдыралар икән.

Тукталышка шыгрым тулган автобус килеп туктый. Шофер алгы ишекне генә ача. Керсәң дә шул ишектән, чыксаң да шул ишектән. Автобус түреннән үк алгы ишеккәчә ырып-ерып үткән пассажирның каны кыза икән, бер дә гаҗәп түгел.

Шулай бервакыт Әлмәттән юлга чыккан В. Захаров рульдә утырган тәкәббер шоферга бик урынлы бер сорау бирергә җөрьәт иткән: нигә ишекләрнең икесен дә ачмыйсыз, моның берәр кагыйдәсе бардыр бит инде, дигән ул. Һәм тозлы-борычлы җавап ишеткән. Шуннан соң В. Захаров Әлмәтнең автотранспорт берләшмәсе (АПОПАТ) җитәкчелегенә хат белән мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булган.

Берләшмә начальнигы урынбасары Ю. Садриев тиз арада аңа бик тә тәфсилле җавап хаты юллаган. Хат болай башлана: «АПОПАТка язган хатыгыз уңае белән шуны хәбәр итәбез: шоферның тупаслык күрсәтүенә Сез үзегез сәбәпче булгансыз...»

Шуннан соң урынбасар пассажирлар йөртү эшендәге кагыйдәләрне ифрат та белдекле рәвештә аңлатып биргән. «Бу кагыйдәләр нигезендә,— дип аерып әйткән иптәш Садриев,— һәр пассажир арткы ишектән керергә, алгы ишектән чыгарга тиеш».

Җавапның ахыры ачулы сүзләр белән тәмамлана: «Иң гади кагыйдәләрне дә белмичә, Сез шоферны аның эш урынында мыскыл иткәнсез...»

Үз кулы астында эшләүче үпкәчел шоферны (җавапта аның фамилиясе күрсәтелмәгән) яклаган чакта, иптәш Садриев бер нәрсәне онытып җибәргән: бу очракта арткы ишек хәтта кешеләрне утыртканда да ачылмаган булган.

В. Захаров «Чаян»га мөрәҗәгать итте. Хатына иптәш Садриевның җавабын да өстәгән иде ул.

«Шыгрым тулы автобустагы пассажирларның болай да авыр хәлен тагын да авырайтырга тиеш түгел бит инде ул кагыйдәләр!»— дип яза В. Захаров.

Әлмәт пассажирының бу мөрәҗәгатен без «Татаравтотранс» берләшмәсенә җибәрдек.

«Шәһәр эчендә һәм шәһәр тирәсендә йөрүче автобуслардан файдалану турындагы кагыйдәләр нигезендә, пассажирлар автобуска арткы ишектән утыртыла һәм һәр ишектән дә чыгарыла,— дип хәбәр итте редакциягә берләшмә начальнигы урынбасары Н. Семенов.— В. Захаровның жалобасына дөрес булмаган җавап биргәне өчен, иптәш Садриевка кисәтү ясалды. АПОПАТ җитәкчелеге В. Захаровтан хат аркылы гафу үтенде».



Кызларның мәхәббәтен яулый алмаган егетләр гадәттә нишли соң? Әйе, мондый җиңелүне һәркем үзенчә кичерә. Кайберәүләр, шагыйрь әйтмешли, «башны салларга салып» каядыр китеп бара, икенче берәүләр шигырь яки көй чыгара... Әнә, җавапсыз мәхәббәт хакында күпме җыр язылган!

Ә менә Казандагы «Медфизприбор» берләшмәсенең сызымчысы, унҗиде яшьлек Олег Павлов бөтәнчәрәк хәрәкәт итәргә булды.

Ял базасында бер кыз белән танышты ул. (Кызның исеме, әйтик, Зәйнәп булсын, ди). Кыз аның белән бүтән очрашырга теләмәгәч, Олег үҗәтлек белән җиңәргә карар кылды һәм Зәйнәпләрнең бусагасын таптый башлады.

Әмма ишекне Зәйнәп үзе түгел, гел әнисе килеп ачты һәм, иплән кенә, кызының Олег белән очрашырга теләмәгәнлеген аңлатырга тырышты.

Тик Олег шулай җайлап кына әйткән сүзләргә дә бик рәнҗеде. Ул үч алырга булды. Олегның күңеле тыныч түгел чакта нишләп әле Зәйнәпләр гаиләсе тыныч яшәргә тиеш?

Башлы егет телефон будкасына керде һәм... Унбиш минутлар үтүгә Зәйнәпләр йорты янына «ашыгыч ярдәм» машинасы килеп туктады...

Бераздан Олег үзенең дус-ишләре белән ниндидер бер вакыйга шәрәфенә шактый гына кәеф-сафа корып алды. Тагын Зәйнәп искә төште. Барлык дус-ишләрен ияртеп, тагын Зәйнәпләргә килде Олег. Аның илчеләренә дә ишекне Зәйнәпнең әнисе ачты. Һәм сабыр гына итеп, вакыт бик соң булганга күрә, кызының алар янына чыга алмавын аңлатырга тырышып карады.

— Әһә, алаймы?!— дип ярсыды гашыйк егет.— Номерны кабатларга туры килә, болай булгач!

Һәм ул тагын телефон-автоматка йөгерде. Дус-ишләре дә иярде. Юк, аны җиңеннән тотып туктату һәм мондый шуклыкларның ахыры бик күңелсез булачагын әйтү өчен түгел. Аларның да шундый әкәмәт маҗарада катнашасылары килде.

Шуннан соң, якын-тирәдәгеләрнең күңеленә шом салып, янгын сүндерү машинасы килеп җитте. Тимер башлык кигән иптәшләр су сиптергеч көпшәләрен сүтәргә дә өлгермәде, «ашыгыч ярдәм» килеп туктады. Зәйнәпнең әти-әниләре врачларга мәсьәләне аңлатып маташкан арада, фатирда халыкка газ хезмәте күрсәтү вәкилләре пәйда булды.

Газ осталары белән аңлашканнан соң, әти кешенең түземе төкәнде:

— Җитте!— диде ул.— Хәзер милициягә шалтыратам!


Әмма милициягә аңардан башка да шалтыратып өлгергәннәр иде инде. Алар да нәкъ шундый ук ялган чакыру алган булганнар икән. Шулай итеп, милиция дә килеп керде.

Хәер, аларны, ялган чакыру буенча килде, дип әйтү бик үк дөрес булмас. Милиция өчен эш бар иде монда. Мондый чакыруларны алар гади шуклык итеп кенә исәпләми шул. Чөнки махсус хезмәт күрсәтүче кешеләрнең шундый шуклык аркасында кайдадыр тоткарлануы кемнәрнеңдер гомерләрен куркыныч астына куя лабаса! Нәкъ менә шуңа күрә дә закон мондый ялган чакыруларны явыз ният белән хулиганлык кылу буларак бәяли. Моның өчен билгеләнгән җәза да шактый кырыс: бер елдан биш елга кадәр.

Их, Олег, Олег! Утырып шигырьләр генә язган булсаң иде син!..

А. ПОТАПОВ.

В. КОСМЫЛИН рәсеме.



— Уйлап табучы Гатинга тагын бер җикереп кенә кара!..

Чаян эзләреннән

«ҺӘЙКӘЛ САЛЫРЛЫК ВАКЫТ»

Шул исемдәге мәкаләдә («Чаян», 18 нче сан, 1983 ел) Менделеевск шәһәрендә яшәүче У. Капитованың фоторәсемнәрен керамикага күчертергә бирүе һәм бик тә болгавыр волокитага юлыгуы турында язылды.

Редакциягә «Татфото» берләшмәсенең баш инженеры Ф. Краснердан җавап килде. Хезмәтне тиешенчә оештырмаганы өчен, керамика цехы начальнигы З. Хәмитов эшеннән алынган.

У. Капитованың заказы үтәлгән.



С. АНДРИАНОВ рәсеме.



— Аның каравы, радиоалгыч эшли башлады!

Э. ГЕЛЬМС рәсеме.



— Әһә, минсез дә булдырдыгызмы!! Минем кирәгем юкмы!! Моннан соң мин сезгә остаз түгел!

Р. ГАТАУЛЛИН рәсеме.



Л. ЕЛЬКОВИЧ рәсеме.



БИЕГЕЗ, ҖӘМӘГАТЬ!

Трамвайдагы мәхшәрдән котылып, җиргә аяк баскан ниндидер абзыйның киемендә хәтта китек бер төймәсе дә калмаган, имеш.

—И-и, абзыкай, бәхетең бар икән әле синең!— дигән аңа контролер.— Кичә синең сыман берәү трамвайга кышкы пәлтә киеп утырган булган. Төшкәч карасa, язгы пәлтә ‧ди моның өстендә! Якасы умырылып төшеп калган... Синекедәй бәхет тәтесә, сөенеченнән күккә сикерер иде ул!

Андый бәхеткә бу абзыкай гына юлыкса, сүз куертып торуның кирәге дә булмас иде.

Казанда яшәүче М. Лепешинский үзенең кыска тунын «Татхимчистка»ның Островский урамындагы 39 нчы йортка урнашкан 1 нче кабул итү пунктына буятырга бирде. Аэрозол ысулы белән әйберләр мануның файдасы турындагы матур реклама белдерүе бер ай дәвамында күп мәртәбәләр төшенә керде аның. Ә соңыннан...

«Кием манучылар янына килгәч,— дип язды редакциягә иптәш Лепешинский,— алар миңа бүтән туннар арасыннан үз тунымны эзләп карарга тәкъдим иттеләр. Тунга таккан бирка кайдадыр төшеп калган булып чыкты. Эзләп табар өчен тунны танырга кирәк бит әле. Көчкә генә таныдым. Төсе әйле-шәйле генә, җөйләре буялмаган, итәкләре куырылып килгән».

— И-и, сезнең бәхетегез бар икән әле!— дип Лепешинскийны котлады пунктның кабул итүчесе.— Югыйсә, бездә болайрак та була...

Һәм ул клиентка икенче бер кыска тунны күрсәтте. Клиент әлеге тун шикелле куырылып килде. Әйе, бәхетсезрәк кешеләр дә бар икән шул бу дөньяда...

Кабул итүче кыз клиентны сөенеченнән бии башлар дип көтте бугай. Әмма клиент дәшмәгәч:

— Их, үз бәхетегезнең кадерен үзегез белмисез, абзыкай!— дип көрсенде ул.— Ә яңадан буямаячакбыз, уйламагыз да. Хәлдән килгәнчә тырыштык инде...

Гомумән, химчисткада эшләүчеләр үзләре манган әйберләрнең нинди төскә керәчәген алдан белеп тә бетерми. Буяуның рәте-юне булмаса, клиентның йөзе нинди төскә керәчәген генә белә алар: кызарып-бүртенеп чыгачак бичара клиент. Манучылар үзләре дә кызарадыр, дип уйласагыз, һичшиксез ялгышырсыз.



Химчистка хур итеп чыгарган мондый туннан Буа шәһәренең Р. Люксембург урамындагы 149 нчы йортка күченеп килгән кешеләр генә баш тартмас иде, шәт. Аларга фасонның да, төснең дә кирәге юк. Җылы гына булсын! Чөнки бу йорттагы батареяларны суыткыч итеп кенә файдаланырга мөмкин.

«Татсельстрой» идарәсенең Буадагы 326 нчы ПМК төзүчеләре килделе-киттеле генә эшләп тапшырган йорт турында сүз бара. Кешеләр күченеп килгәндә, бу йортта сантехника узелы тоташтырылмаган иде. Кайбер фатирларда раковина белән ваннаның эзе дә күренми. Су юк. Шпингалетлар, йозаклар, ишек тоткалары... Кыскасы, юк әйберләрдән дә күп әйбер юк иде бу йортта. Ә ни генә бар иде соң монда, алай булгач? Әз генә яңгыр төштеме — лычма суга бата торган почмаклар, түшәмнәр, тәрәзә төпләре һәм пыяласы ватык тәрәзәләр, буялмаган идәннәр бар иде.

Газ мәсьәләсенә килгәндә... Шыпырт, җәмәгать, кычкырып әйтә күрмәгез. Монда газ плитәләре бар барлыкка. Ләкин газ тоташтырылмаган. Шуңа күрә монда яшәүчеләр баллоннардан файдаланырга мәҗбүр булдылар. Куркынычын куркыныч та бит, нишлисең инде?..

Бу йортка күчеп килгән кешеләрнең сөенечтән биемәгәннәрен күргәч, ПМК начальнигы Я. Шәңгәрәев көрсенеп куйды.

— Бәхеткәйләрегезнең кадерен белмисез бит!— диде ул.—«Тәрәзәсе юк, ишеге юк, эче тулы халык» дигән табышмакны ишеткәнегез бармы? Йортыгыз шундый булса, нишләр идегез? Ә бу йортта, шөкер, ишекләр дә, тәрәзәләр дә бар. Бәхетле кешеләр сез!

Әгәр сезгә шундый ягымлы сүзләр әйтәләр икән, хәлегез никадәр авыр булса да, биегез, җәмәгать! Рәнҗемәгез дә, зарланмагыз да, сөенәсөенә биегез. Бәхетле булуларга ни җитә!

Р. ФӘЛӘХОВ.



Яндырды илһам ялкыны



Рәхимә Фатыйховна Попченконың рәсем ясауга, сурәт төшерүгә хирeслеге барлыгын автовокзал кассасында эшләүчеләрдән берәү дә белми иде. Хәер, шундый сәләткә ия икәнлеген хәтта үзе дә белми иде ул. Бу өлкәдә махсус белеме дә булмаганлыктан, үз гомерен сәнгатькә багышлау турында уйлап та карамаган иде Рәхимә Фатыйховна.

Илһам ялкыны кайчакларда гади кешеләрнең дә күңелләрен ут итә икән шул! Рәхимә Фатыйховнага да күктән илһам иңде. Кергән акчаны тапшыру өчен язылган квитанциягә ул саклык кассасының мөһер сурәтен төшерде. Балкып тора мөһер дигәнең! «Иксез-чиксез синең көч-кодрәтең, галиҗәнаб сәнгать!» — дип дулкынланып пышылдады ул.

Мондый «иҗат»ның әҗере дә мул булырга тиеш иде. Контроль-ревизия органнары гына күз тидерә күрмәсен. Рәхимә Фатыйховна үзенең исәп-хисап язуларын ПОПАТның өлкән инженеры Ф. Мөхәммәтшинага тапшырган чакта киеренкелек соңгы чиккә җитте. Инженер кулларын чәбәкләп куйды һәм: «һай, Рәхимә, көзгегә күз салчы! Битең мөһер буявына буялып беткән бит! Ә кулларың... Аһ! Аһ!» — дип үрсәләнде.

Кыңгыр эш Рәхимә Фатыйховнаның йөзенә үк чыккан иде. Бер кызарды, бер агарды ул. Әмма зилзилә купмыйча калды. Мөхәммәтшина сәнгатьтә сирәк йөзә иде бугай. Аннары, күзләренең үткенлеге белән әлләни мактанырлык булмаганга күрә, ул Рәхимә Фатыйховнаның тез буыннары ничек калтыранганын шәйләмичә калды, ахры. Ни генә булмасын, исәп-хисап язулары кабул ителде. Шунда иҗатка иркен юл ачылды. Квитанциягә мөһерне маташтырып куясың да, акча — кесәгә! Оҗмах, билләһи.

Ләкин Рәхимә Фатыйховна даһилар белән беррәттән урын алырга чамасыз ашыкты, күрәсең. Аның ашык-пошык кына ясаган «әсәрләр»ен кырысрак рецензентлар — тикшерү органы кешеләре күреп алды. Алар гап-гади кучермә әсәрләргә юлыкканнарын гап-гади күз белән дә чамаладылар. Җитмәсә, күчермәләрнең бик тә булдыксыз куллы кеше тарафыннан эшләнгәне әллә каян беленеп тора. Алай да шушы күчермәләр аркасында 13 мең сум дәүләт акчасы Рәхимә Фатыйховнаның кесәсенә күчәргә өлгергән иде инде.

Аңардан аермалы буларак, Анатолий Владимирович Селюков рәсем сәнгатенә карата вакчыл мөнәсәбәттә булмады. Акча кызыксындырмады аны. Селюковны иң борчыган нәрсә хезмәт кенәгәсендәге «Прогуллары өчен эштән куылды» дигән ямьсез бер язу иде. Бу язуның кырыенда ук — статья, мөһер. Барысы да тиешенчә. Бер дә ошамады болар Селюковка. Двигательләр заводының кадрлар бүлеген эттән алып беткә сала-сала каргады да әлеге ямьсез язуны юк итте ул. Аннары шул урынга үзенең күңеленә хуш килердәй сүзләрне язып куйды.

Ә менә Сергей Николаевич Рябчиков моннан да кәттәрәк уңышларга ирешә. Аның сәнгати хыялына Рембрандт үзе дә сокланыр иде, мөгаен. Иректән мәхрүм ителгән еллары хезмәт стажына керту күпкә кулайрак булыр, дигән нәтиҗәгә килде ул. Әйтте дә, булдырды да. Әкияттәге кебек килеп чыкты. Абзагыз үзенең хезмәт кенәгәсенә кул тидергәннән соң, гаҗәеп күренеш барлыкка килде. Баксаң, Рябчиков җинаять тә эшләмәгән, җәза да алмаган, ә бәлки тирләп-пешеп удар тәзелештә эшләп йөргән икән бит!

...Каләмнәр кыштырдый, кәгазьләр шыштырдый...

«Сәнгать осталары» документларда ниләр генә сурәтләп күрсәтмиләр, әй! Моңарчы инде бер мәртәбә өйләнгән булуыгызны белдертәсегез килмиме? Рәхим итегез! Савыкмастай чиргә юлыкканыгызны расларга белешмә кирәкме? Мәгез, әле карасы да кибеп бетмәгән. Бәй, прогул ясадыгыз мыни? Борчылмагыз, менә сезгә бер повестка, башлыкларыгызга, бик җитди оешмага чакырганнар иде, дигән булырсыз. Нәрсә, хата киткән мени? Ничек күреп алдыгыз әле аны? Ә-ә, мөһердәге язуда мыни? Гафу итегез, алай гына булгалый инде ул...


Мондый чакларда гафу үтенеп кенә булмый шул инде. Чөнки «сәнгать»нең мондый төре җинаятьләр кодексының тегеләй бу статьясына туры килә. Һәм аның өчен җәзаның тегеләй бу төре билгеләнә. Монысын инде халык суды билгели.

Р. ФӘРХЕТДИНОВ,
Брежнев шәһәр Советы эчке эшләр идарәсенең тикшерү бүлеге начальнигы.

А. АЛЕШИЧЕВ рәсеме.



И. СОПИКОВ рәсеме.



САТУЧЫНЫҢ АЛТЫН СҮЗЕ

Даурская урамындагы мебель кибетендә мин китап стеллажы сатып алдым. Акча түләү белән үк өйгә китерту мәсьәләсен дә 854758 нче номерлы квитанция белән рәсмиләштереп куйдым. Шулчак бер сатучы кыз миңа сәер генә киңәш бирде.

— Сез, машина килеп җитмичә торып, китә күрмәгез берүк, — диде ул. — Элгәре шофер белән килешегез. Мебельне сезнең Химиклар урамына китерергә риза булмавы да бар бит әле аның...

Ничек инде, мин әйтәм, риза булмаска тиеш?! Ниндидер бер кырыктартмачы сәүдәгәр белән түгел, мөхтәрәм дәүләт фирмасы — Таттрансагентлык белән эш йөртәм ләбаса мин!

Кыскасы, сатучының киңәшен тотмадым. Өйгә кайттым да стеллажга урын әзерләргә тотындым. Ләкин бер көн үтеп китте, ике, өч көн... Стеллаж өчен урын да әзер, мин генә үземә урын таба алмыйм. Трансагентлыкка шылтыратам. Алар исә, шаккатып:

— Бәрәч, китермәделәр мени әле? — диләр. — Ярар, ярар, көтегез, тиздән китерерләр, боерган булса...

Тагын көтәм китерүләрен. Бер көн, ике көн, өч көн... Эштән сорап калуы да оят хәзер. Үз хисабыңа ял сора, дим хатынга.

Уникенче көн киткәч кенә безгә бернечә җор егет шаулый-гөрли килеп керде. «Юабызмы соң?» — диешә-диешә стеллажны кертеп куйды алар.

Их, сатучының сүзләре алтын булган икән бит, туганнар!

В. ГЛУХОВ.
КАЗАН.






Мәгълүм булганча, хатын-кыз бар яктан да күркәм: төсе-бите, киеме-салымы дисеңме, холкы-фигыле, уй-фикерләре дисеңме — һәммәсе дә гүзәл! Әмма шулай да хатын-кызны иң нык бизәгәне — аның назлы һәм ныклы куллары. Хатын-кызның килеш-килбәте соклангыч икән — шушы кулларның тырышлыгы нәтиҗәсе ул, беләсегез килсә! Он-талкан ясарга, утлы табага бастырырга, игәүләп-сыйпап алырга сәләтле бу куллар. Гаилә тормышының барлык ертык-сүтек урыннарын шушы куллар ямап-типчеп тора. Буш вакытларда исә авызга кабуга эреп китәрдәй каз бәлешләре генә түгел, төртмәле хикәяләр һәм борычлы рәсемнәр дә пешереп өлгертә белә алар. Журналның бу битләрендә укучыларыбызга хатын-кызларның үз бәйрәмнәре хөрмәтенә әзерләп өлгерткән әнә шундый сыйларыннан авыз итәргә җай чыгып тора бит әле, җәмәгать!

Тәмле булсын!

ЧАЯН.



(Хикәя

Рәхилә һәр нәрсәгә үзе баш, үзе түш иде. Беренче балалары тугачтын да бишекне өйнең кайсы урынына, колясканы кая куярга, бала караватын кайда урнаштырырга бәхәс купкач, Әхмәдулланың үзенең баш икәнен белдереп аласы килсә дә, муен гына булырга тиешле Рәхилә барыбер җиңде. Әхмәдулла бишекне иң уртага эләргә, бала караватын да кыл уртага, колясканы да бөтен кеше күрерлек түргә куярга теләгән иде. Бишек элдереп тә тормады Рәхилә. Бала караваты мич янынарак стена буена куелды, коляска да мич арасына кереп посты. Дөрес, вакыты белән идән уртасына да, урам уртасына да чыкты коляска, тик төп урыны барыбер шунда булды.

Тагын бер бала дөньяга килгәннән соң да Рәхилә үзе хәл итеп куйды:

— Өченчене алып кайт, дип тыныңны да чыгарма!

Инде гомерләр үтте, ике бәләкәч тә үсте һәм бер-бер артлы кияүгә чыктылар. Әхмәдулла белән Рәхилә алты почмаклы йортта икәү яшәп калдылар. Икәү генә калсалар да, Рәхиләнең күңеле күтәренке, Әхмәдулла да тормышыннан канәгатьсезлек күрсәтергә җай таба алмас иде — аның тормышында адәм баласы үзен бәхетле сизәрлек бөтенесе дә бар: ул урын-җир дисеңме, ул кием-салым дисеңме, ул җиһаз, йорт-җир, абзар-кураны әйткән дә юк инде. Әмма барыбер нидер җитми Әхмәдуллага, ни икәнен үзе дә әйтеп бирә алмый. Һәм бу үзе дә белмәгән китеклек ни гомер аның күңелен кимерә, ай, кимерә генә...

Бердәнбер көнне Әхмәдулла авыл урамын тутырып басуга барганда, аның юлына Миңсафа түти чыкты. Йөгерә иде, тыны кысылган иде түтинең, ничек тә булса сөенечле хәбәрне тизрәк тапшырасы килүе булгандыр: район үзәгендә яшәүче олы кызының малае туган, Әхмәдулланың оныгы!

Әхмәдулла бер мизгел туктала алмый торды, тукталгач, атлап китә алмады, аңлап алгач, Миңсафа түтине каршыдагы кибеткә алып кереп тә китте. Менә бит аңа нәрсә җитми икән, онык кирәк булган Әхмәдуллага, онык! Бәби сөяргә сагынган икән Әхмәдулла! Күз явын ала торган бизәкле чуклы олы кәшимир шәлне түтинең башына бәйләде, сатучыдан бер ярты алып кесәсенә тыкты да, басуга китәсе урында, хатыны эшли торган ындыр табагына менеп китте.

Рәхилә дә эш урынында түгел иде, аңа да бу хәбәр ишетелгән. Әхмәдулла да бер югары очка менгәч, тиз генә басуга китә алмады — үлчәүче Хәйрулла абзый белән бер яртыны закускасызнисез бөгәрләп ташладылар, тик бу кече телгә дә җитми калды.

Әхмәдулла кабат өйләренә кайтып китте һәм хатынын бары-
бер тапты. Рәхилә ашык-пошык
иде, Әхмәдулла орчык кебек ке
рендә әйләндерә башлады. Әзмә
кән Рәхиләнең күзе әйле-шәйле к
лән бергә өйдәге җиһаз да әйлә
тартма итеп өеп куелган, күпме
алынган Балтик буенда эшләнгән
Аларны әле җыеп куярга Әхмәд
чектер җайлары табылмый иде.
мас, кайчан булса да зал түренә
гы һәм идәндәге кыйммәтле кел
басып йөрмиләр, аллы-гөлле чәч
йөрергә күңелләре кушмый иде.
аяк белән баскач, чәчәкләре изеле

Бу сөенечтән әйләнгәндә пала
да керелде һәм аңардагы чәчәклә
бәргәләнделәр дә бәргәләнделәр.

— Имансыз, паласны таптый
хилә.

— Һи, карчык, хәзер без ань
тәбез!— диде Әхмәдулла.

— Кит аннан, затлы келәмне
дип мыгырданды Рәхилә.

Бәлки, ул аны болай гына,
өчен генә әйткәндер, әмма әле
дуллага исә бу җитә калды, ул к
хиләгә, бер паласка карап торды
шып алды. Кычытканнан түгел и

Ул бер мизгел эчендә оныгы
карады. Шул арада йомшак к

З. САДЫЙКОВА рәсеме.



Клара БУЛАТОВА

* * *

«Эт күңеле,— диләр,— бер сөяк»,
Әмма хәзер тыйнак этләр сирәк.
Маэмайларның күңелен табу өчен
Сөяк-санак түгел... түшкә кирәк!

С. ФӘТТӘХОВА рәсеме.



Халисә НИГЪМӘТУЛЛИН



Бухгалтериядәге хатыннар
ләптер бүген ирләреннән за
нып утырды.

— Акча табу белән генә
мый ул, бала тәрбияләүгә кат
магач,— диештеләр алар.— Х
ге этиләрнең этилеге ташка ү
генә...

Шәмси уйга калды. Хак
сөйлиләр бит бу чүпрәк баш
валлаһи хак сүз... Әйтик,
Шәмси үзе. Кызын бакчага ур
тырганда да бармады бит ул.
лефоннан гына сөйләштеләр
лештеләр дә — вәссәлам!

— Җитте!— диде Шәмси
дына.— Хатынның һушын ал
әле бүген. Баланы үзем алып
тыйм әле бакчадан. Югыйсә
да эшендә минем хакта шунды
гайбәт чәйнәп утырадыр.

...Күзләре шар булган, ты
буылган Шәмси килеп керг
алтынчы группадагы бал
урамга чыгарга киенәләр иде

— Хәлилова Ләйсән,— диде

— Юк бездә Хәлилова Ләйс
диде тәрбияче.

— Ах, шулаймы?!

Аның артыннан ишек кенә
пылдап калды. Туп-туры мө
нең үзенә барып керде.

Сәмига СӘҮБАНОВА

ЫК

үчтәнәчләрен төенчеккә төйни хатынын бүрәнәдәй беләклә- дәй Әхмәдулла кулына эләк- нде, башы әйләнде, Рәхилә бе- башлады. Бер читкә тартма- кыенып та күптән түгел генә мебель гарнитуры да әйләнде. лланың да, Рәхиләнең дә ни- ичава, өйгә кергәч, кире чык- реп утырырлар әле. Стенада- нәр дә әйләнде, идәндәгесенә әре булган бу keләмне таптап ердән, бик затлы, икенчедән, китәрләр кебек...

читенә дә басылды, уртасына көчле җил вакытындагы кебек

ң бит!— дип ыңгыраШты Рә-

өстеннән бәләкәчне мүкәйлә-

бала кәкәй иттерәмме соң?!—

хмәдулланың сүзен сүз итмәс ондициясенә җитмәгән Әхмә- сәк туктап калды һәм бер Рә- бер үзенең муенын кашып-ка- , билгеле, муенын кашуы. ләп палас бәясен чагыштырып ат белән паластагы гөлләрне сыйпап иркәләгән Рәхиләсен күрергә дә өлгерде. Тузанын гына себермәкче булды микән әллә чәчәкләрнең аяк астында тирбәлүләренә дә эче пошты микән хатынының? Ни булса булгандыр, Әхмәдуллага җитә калды, аның болай да урыныннан купкан йөрәге дулый башлады. Ул бит гомер буена Рәхиләне үзенең башыннан кадерлерәк күрде, хатынының «мин баш» дип чын күңелдән ышануына да мыек астыннан көлеп кенә йөрде. Ләкин яңа гына туган оныгын шул идәнгә җәйгән нәмәстәдән кадерлерәк итеп хатынының юри генә булса да чагыштыруы аны чыгырыннан чыгарды. Белә иде Әхмәдулла, Рәхилә моны юри генә әйтә, дөньяга килгән оныгы аңа да якын, якын булмаса, ашыгаашыга төенчек төйнәмәс иде. Ләкин ни булса булсын, ни итсә итсен, әмма ике арадагы сүздә үзен өстен калдырыр өчен, оныгын юри генә ким итүенә шатлыгы чамадан ашкан Әхмәдулланың түзәр чамасы юк иде.

Әхмәдулла шул ачуыннан Рәхиләнең үз җаена, үз көенә урнаштырган әйберләрен мамык кебек кенә очырта башлады. Муен урынына йөргән башның болай үз позициясен алырга тырышып тузынуын күреп, моңа хәтле баш урынында йөргән муен, берике тапкыр Әхмәдулласының кулын тотып калырга талпынса да, булдыра алмады. Зәмһәрир җилләре исә, якын да килерлек түгел иде — Рәхилә төенчекне кулына эләктереп урамга атылды да район үзәгенә элдертте.

Кинәт Әхмәдулла да тагын исенә килде, ул да эре-эре атлап юлга чыкты. Юл тыныч иде, бер машина да очрамады. Хәер, сигез чакрымлык ара күңел ярсып алган чакта сизелә мени ул...
Әхмәдулла Рәхиләне ярты юлда куып җитте.

— Карчык, төенчегеңне бир,— диде ул йомшак кына.— Арыгансыңдыр.

Рәхилә аны-моны эндәшмәде, төенчекне Әхмәдуллага сузды. Әхмәдулла бер кулына төенчек тотты, икенчесе белән Рәхиләсен җитәкләде.

Рәхиләгә исә чиксез рәхәт иде. Менә бит ул, юләр, гомер буена хатын баш дип Әхмәдулласы аны болай гына, юри генә үсендергән икән. Баш булган икән, баш икән аның Әхмәдулласы!

Әйе, бәхетле иде Рәхилә. Тиздән алар үзләренең беренче оныкларын күрәчәкләр. Тиздән ул бәләкәч чәчәкле келәм өстендә тырыша-тырыша мүкәләп йөрер.

Дөнья якты! Рәхиләнең янында ире — гаилә башлыгы, арка таянычы — Әхмәдулласы атлап бара.

К. НИЗАМИЕВА

Тикшерү килде

Мәсәл

Конторада тыныч кына эшләгәндә
Портфель йөрткән һәрбер җанвар, һәрбер киек,
Көтмәгәндә югарыдан — Арысланнан
Бик тә усал Тикшерүче төште килеп.
Берәм-берәм тикшерде ул һәммәсен дә
Һәм, ниһаять, Ишәккә дә җитте чират,
Ә соңыннан Тикшерүче әйтеп куйды:
— Бу да портфель йөртә мени? Бу бит — дурак!
Үпкәләде шулчак Ишәк: «И-а!— диде.—
Бу яман сүз нигә бары миңа?!— диде.—
И, иптәш кем, колагыңа элеп тор син,
Тегесе — шундый, бусы — мондый, белеп тор син».
Төрле-төрле юк-барларны тезде Ишәк,
Контораның барлык халкын изде Ишәк.
«Ишәк кенә икән монда юньле эшче!»—
Дип актлар төзеп китте Тикшерүче.
Бездә дә бит нәкъ шул Ишәк ишеләр бар —
Кара ягып ак калучы кешеләр бар.

САБА РАЙОНЫ.



Е. ХИТРОВА рәсеме.



— Жалобалар кенәгәсен китерегез!..

С. ПРИВИНА рәсеме.





мореска

— Әйдәгез, әйдә,— диде мөлаем мөдир,— рәхим итегез! Ни йомыш?

— Йомыш зурдан! Баланы кая куйдыгыз?!

Мөдирне күр син, бал корты чакты, диярсең, коридорга атылды. Ишек төбендә үк завхоз белән бәрелешә язды.

— Бакчабыздан бала югалган!— диде хәлсезләнгән мөдир.

Шәмси мөдир бүлмәсеннән чыкканда, коридорда кеше шактый күп иде. Араларында шушы бакчада тәрбияче булып эшләүче күршесе Рәшидә дә бар.

— Исәнме, Шәмси!— диде Рәшидә, гаҗәпләнеп.— Син монда нишләп йөрисең?!

— Баланы алырга килдем! Ә бала юк, шайтан алгыры! Кая ул?!

— Кая булсын? Синең бу бакчага йөргән улың күптән мәктәптә бит инде!

— Малайны түгел, кызны алырга килдем мин!

— И-и, күрше, кызың бүтән бакчага йөри ләбаса!..

Булмаса булмый икән инде — гайбәт янчыгын чишәргә тагын җай чыкты чүпрәк башларга...

Уены-чыны бергә

БҮЛҮ

Борын заманда бер хатын казый катына бара, имеш.

— Ирем белән аерылышабыз,— ди ул.— Кием-салымны, савыт-сабаны, бала-чаганы бүлегезче.

Казый мәсьәләне тиз хәл итә.

— Киеме — иреңә, салымы — сиңа, савыты — иреңә, сабасы — сиңа, баласы — сиңа, чагасы — иреңә...

Р. ЗИННУРОВА.

КАЗАН.



А. ГАТАУЛЛИНА рәсеме.



Аулак урын

Алиментган качып йөрүче кайбер вөҗдансыз кешеләр дә бар бит әле бездә, җәмәгать. Алар үзләренең элеккеге гаиләләре һәм суд башкаручылары белән очрашмас өчен бөтен ил буйлап килеп саралар.



Әгәр дә Лаеш районындагы бер аулак урын барлыгын белсәләр, алар ул кадәр интегеп йөрмәсләр иде. «Победа» колхозында алар тыныч кына гомер кичерерләр иде, мөгаен. Күптән түгел генә ачыкланганча, В. Карусева җитәкчелегендәге бухгалтерия монда алимент-фәләнне генә түгел, хәтта керем налогын тотып калырга да онытa икән. Мисал өчен, сөт җыючы Ф. Исмәгыйловадан менә ун ел инде сукыр тиен дә налог тотылмаган. Узган елның сигез ае дәвамында гына да бухгалтерия аңа 439 сум акчаны янда калдырырга мөмкинлек биргән.

Ш. СӨНГАТОВ.

Археологларга сөенеч

Археологларның эше бер дә җиңелдән түгел бит, җәмәгать. Көне буе, төне буе казыйлар да казыйлар. Тутыгып беткән берәр торба кисәген казып чыгарасылары килә. Шулай итеп борынгы шәһәрнең су үткәргечле булганлыгын исбатламакчы алар. Кем дә булса жәллиме археологларны!

Әйе, андый кешеләр дә бар бугай. Әнә, «Полимерфото» заводының ЖКО хезмәткәрләрен генә (начальнигы А. Галиев) алыйк.

Безнең Левченко поселогында (Казанның Мәскәү районы) җәй көнне үк траншея казыганнар иде. Көз кергәч эшчеләр ул траншеяга җылылык трассасы торбаларын сузып салдылар. Салдылар да китеп бардылар. Торбаларын күмеп тә тормадылар. Урамдагы колонкаларга тоташкан су үткәргеч участогы да ачык килеш калды.

Сүз дә юк, бу хакта без ЖКОга әйтеп карадык. Салкыннар башлануга су үткәргеч торбалары шартлап ярылачак бит, дидек. Ыжламадылар да!

Гасырлар үтәр... Археологлар әлеге торбаларга килеп төртелерләр. Куанычларыннан түбәләре күккә тияр инде аларның. Таптап күмеп, асфальт җәеп куйган җирне казуга караганда, әрем генә күмеп киткән җирне казу алар өчен уен гына булачак бит!

Е. БОЛЬШОЙ.



Р. S. «Чаян» корреспондентының заводка шалтыратуы булды, траншеяларны күмәргә дә тотындылар. Кышкы җайсыз вакыт булуга карамастан, ике көндә күмеп тә бетерделәр...

Үпкәли яздым



Бик тә кунакчыл кеше минем дустым. Кунак ашы — кара-каршы, дигәндәй, мин дә бурычлы булып калмыйм, әлбәттә. Ләкин соңгы вакытта кунакка йөрешүебезнең рәте-чираты китте.

Дустым үзенең хәләл җефете белән бездә соңгы тапкыр кунакта булып киткәннән соң өч ай вакыт үтте. Никтер безне чакырмыйлар болар. Дустым мәсьәләне аңлатырга өлгереп калмаса, үпкәли идем, валлаһи.

— Ачулана күрмә, дускай,— диде ул, оялып кына.— Бер чынаяк чәйгә дә чакыра алмыйм сезне. Дүрт ай инде өйдә су юк. Бөтен подъездыбыз белән сусыз утырабыз. Суыгы да юк, кайнары да...

Менә бит хикмәт нәрсәдә икән! Дустымны юатырга тырыштым. Ул гаепле түгел бит монда. Аның йортын (Тынычлык урамы, 17 нче йорт) су белән тәэмин итәргә тиешле кешеләр оялсыннар әнә!

Без барыбер дустыбызга кунакка бардык баруын. Үзебез белән ике литр сыешлы термоска чәй тутырып алдык. Рәхәтләнделәр чәйгә бичаралар!

Р. ВӘЛИЕВ.

ӘЛМӘТ.

Читтән-читтән генә



Трансформатор пунктларына гадәттә искәртү язуы элеп куялар. Янәсе, үрмәләп менә күрмә, тәпиеңне сузачаксың!

Ә менә безнең трансформатор пункты ишегендә андый язу юк. Хәер, кешеләр аны болай да читләтеп узарга тырышалар. Аннан-моннан гына эләктереп куелган үткәргеч чыбыкларын, калҗаеп-изелеп беткән щитокны һәм авып төшәр хәлгә җиткән тирәү баганаларын күргәч бу тирәгә аяк басмаска ант итәрсең.

Монда яшәүчеләрнең трансформаторны читләтеп үтүләре аңлашыла. Ә менә Биектау подстанциясенең электриклары нишләп бу тирәне читтән урап үтә икән соң! Без аларның трансформатор пунктында соңгы мәртәбә кайчанрак күренгәннәрен дә хәтерләмибез инде.

А. ЩЕГОЛЕВ.

БИЕКТАУ РАЙОНЫ,
ЗУР КЛЫКИ АВЫЛЫ.



Тәпи-тәпи

Берзаман кемдер, хат яздырып алмакчы булып, Хуҗа Насретдин янына килгән икән.

— Булмый, туган,— дигән Хуҗа.— Аягым сызлый...

— Син кул белән язасың лабаса, хода бәндәсе!— дип шаккаткан теге кеше.

— Шулаен шулай да,— дигән Хуҗа.— Минем язуны үземнән башка беркем дә танымый бит. Хатны үзем алып барып, укып бирергә туры киләчәк...

Аякның саулыгы белән хат-хәбәрләр алу мәсьәләсендә безнең Самсоновка поселогы халкы белән сөйләшеп карагыз сез. Ишетмәгәнегезне ишетерсез!

Хикмәт шунда: халык саны аз, дигән булып, безнең элемтә бүлекчәсен яптылар. Хәзер бу поселокка ун чакрым ераклыктагы Ширәмәт элемтә бүлекчәсе хезмәт күрсәтә. Ләкин почтаны китерү эше юлга салынмаганлыктан (йә ат булмый, яки трактор ватыла), газета-журналларны, хат-хәбәрләрне алып кайтыр өчен Ширәмәт белән ике арада еш кына тәпи-тәпи йөрергә туры килә.

Поселокта яшәүчеләр исеменнән
А. НИКОЛАШКИН.

ТҮБӘН КАМА РАЙОНЫ.



КҮҢЕЛЛЕ КУНАКЛАР



Н. КАКАБАЕВ рәсеме.
«Токмак», Ашхабад.



Ф. САМУКАС рәсеме.
«Шлуота», Вильнюс.












В. ЮЖНЫЙ рәсеме.
«Капкан», Чабаксар.



— Ниткән бүләкләр бу! Бүген минем туган көн мәллә!

Н. МАЛОВ рәсеме.

«Крокодил», Мәскәү.



— Бәйрәм котлы булсын!

О. МОНАСТЫРСКИЙ рәсеме.
«Перец», Киев.










— Хәзер инде үзем сатып алган бу әйберләрне миңа бүләк ит тә, бәйрәм белән котла!..

В. ИГНАТЬЕВ рәсеме.



— Көн саен кача-поса килә дә бездән күчереп ясый. Аннары тизрәк институтына йөгерә...

КИЯҮ БАЛАКАЙ



(Җәй хатирәләре)

Оешкан рәвештә ял итүгә ни җитә, дуслар! Кемдер сезнең өчен поездга яки самолетка билетларны алдан хәстәрли, ял итәсе урынга илтә бара, ашау-эчү, торак белән тәэмин итә һәм соңыннан янә өегезгә кайтарып куя... Дөнья рәхәте! Шуңа күрә дә без, Брежнев шәһәренең сәяхәтләр һәм экскурсияләр бюросы аша Пицундага турист путевкалары алу мөмкинлеге килеп чыккач, бик тә куаныштык.

Егерме көн буена рәхәтләнеп диңгездә коендык, кызындык, көч җыйдык. Ә аннары кайбер сораулар күңелне тырный башлады. Өйгә кайтып егылганчы эзәрлекләде безне алар. Диңгез буе комлыкларыннан безне никтер бер көнгә алданрак кузгаттылар. Нигә? Ни булды? Аңламадык.

Нишләп без алдан әйтелгәнчә Адлердан турук Казанга яки Бигешкә түгел, ә бәлки Мәскәүнең Внуково аэропортына очтык?

Монда килеп төшүгә группа җитәкчесе Анатолий Леонтьевич Невечеряны каршыларга машина килде. Ул үзенең хәләл җефетен һәм аның ахирәтен шул кара «Волга»га утыртты да каядыр китеп югалды. Җитәкчесеннән мәхрүм калган группа, ничек кирәк алай, Внуководан Домодедовога барып элгәште. Ниятебез — шуннан Бигешкә очу. Группа җитәкчесе бу ниятне ничегрәк тормышка ашырырга икәнен дә өйрәтмәде хәтта. Җитмәсә, кабалана торгач, ул ирле-хатынлы бер гаиләнең багаж квитанциясен дә үзе белән алып киткән булып чыкты. Ярый әле туристлар югалып калмады. Күмәк көч белән тырыша торгач, ул әйберләрне алу бәхетенә ирештек. Бер саквояж гына югалды.

Домодедовода уналты сәгать буена Аэрофлотның каты утыргычларында каңгырырга туры килде.

Мең газаплар белән төнне дә үткәрдек...

Самолетка утырыр алдыннан гына безнең могтәбәр җитәкчебез килеп төште. Ял иткән, шәпләп кырынып алган, «Очыш» дигән ислемай сөртенгән. Баксаң, ул Мәскәү кешесе икән. Һәм ул Домодедовода эшли, имеш. Менә сиңа мә! Җылы өендә йокы туйдырып килгән җитәкчене беркем дә алкышлап каршыларга теләмәде, әлбәттә. Киресенчә, аны күрмәмешкә салыштык.

Экскурсия бюросы группаны нишләп шундый ышанычсыз кешегә ышанып тапшырган соң? Аннары, гомумән, махсус әзерлеге булмаган һәм бүтән шәһәрдә яшәгән килеш группа җитәкчесе булырга аның ни хакы бар? Бу сорауларга безнең әле дә җавап таба алганыбыз юк.

Ирле-хатынлы Черковлар, Федосенко, З. Поликарпова.

РЕДАКЦИЯДӘН. Брежнев шәһәренең сәяхәтләр һәм экскурсияләр бюросы директоры Анатолий Якимович Артемьев үзенең адашы Анатолий Леонтьевич Невечеряны һич тә әзерлексез кеше дип исәпләми. Тиешле курсларны тәмамламаса да, группа җитәкчесенә тиешле категориясе булмаса да, Невечеря бик тә әйбәт җанлы һәм гаять тәҗрибәле кеше, дип аңлата Артемьев. Өстәвенә, Невечеря аэропортта самолетлар хәрәкәтенә хезмәт күрсәтүче диспетчер булып эшли икән. Кыскасы, кирәкле кеше, үз кеше! Билет юнәтү дисеңме, туристларны самолетка урнаштыру дисеңме — барысын да булдыра ала.

Аның туристлар өчен ниләр булдыра алганын күрдек инде. Невечеряны үз кеше дип әйтеп Артемьев бер дә ялгышмый. Чыннан да, үз кеше ул аңа. Кадерле кияве, ягъни мәсәлән!

«Кияү булгач, аңлашыла инде,— дияр кайбер укучыларыбыз.— Экскурсия бюросы хисабына чираттагы ялны Кара диңгез буенда, коннәрнең иң әйбәт чорында кызынып уздыру — рәхәт нәрсәдәр инде ул. Җитмәсә, тән кызына тора, хезмәт хакы бара тора...»

Монда бер нәрсәне истә тотарга кирәк: экскурсия бюросында группа җитәкчесе булып эшләү — гаять җаваплы һәм мәшәкатьле эш. Әгәр бу эшне намус белән башкарса, хәтта оҗмах бакчаларына ясаган сәяхәттән дә арып-йончып кайта группа җитәкчесе. Ләкин, кабатлап әйтәбез, намус белән, көчеңне кызганмыйча эшләсәң генә шулай ул. Артемьевның кияве шикелле кыланмасаң гына...

Камил ФАЗЛЫТДИНОВ

ӘЙДӘҮЧЕ

Яныл-пешеп, тиргә чумып,
Селтәп ялтыр чалгылар,
Кычыткан чаба егетләр,
Һич тә армый-талмыйлар.
Монда килгән һәммәсе дә,
Хәтта Ялкау Мөслим дә.
Бүген Пошмас Мөхетдинне
Уза алмый һичкем дә.
Болармы соң хөрәсәннәр!
Эшлиләр ду китереп.
Һәркайсысын әйдәп тора
Ялкау Мөслим җикереп:
— Калдырмагыз сабагын да,
Җирне кырып чабыгыз.
Кесә тишегеннән төшкән
Шешәне тиз табыгыз!

Аннан-моннан

Әби сөйләп утыра:

— Без яшь чакта урманда җиләк бик күп булыр иде. Аланына ялан тәпи керсәң, аяк тырнакларың кып-кызыл булып чыгар иде. Хәзерге кала хатыннарыныкы кебек...

* * *

Бар көнбагышлар — суны беләк юанлыгы сабак аркылы эчеп үсәләр дә, ач булалар. Бар башаклар — дымны салам аркылы гына суырып үсәләр дә, тук булалар.

* * *

— Кәртинкәдә барысы да ал да гөл була инде аның... Анда, әнә, хәтта Кабан күленнән дә өр-яңа буяу исе килеп тора, апаем!..

Марс АХУНОВ.

Казан.



●

— Ирегезгә моннан соң бернинди эштә дә эшләргә ярамый,— ди врач бер хатынга.

— Шуны үзенә әйтимме соң! Сөенеченнән менә хәзер үк савыгып китәчәк!

●

— Гаепләнүче, кем булып эшлисез!— дип сорый судья.

— Акробат мин.

— Кем якынрак анда, тәрәзәне ябыгыз әле.

●

Бер ханым ресторанда официантка мөрәҗәгать итә.

— Әйтегезче, әлерәк кенә лимонад китергән мут күзле официанткагыз кая югалды!

— Сезнең әчәсегез киләме әллә!

— Юк. Иремне табасым килә...

●

— Сыраханәдә озаграк утырып кайтсам, хатыным минем белән өч көн сөйләшми.

— Еш соңлап кайтасыңмы соң!

— Юк ла инде! Өч көнгә бер генә.

●

Ике аучы сөйләшә.

— Куянга дүрт йөз метрдан да атам мин.

— Сөйләмә юкны! Дүрт йөз метрдан кем куянга тидерә алсын ди!

— Тидерәм, димим ич мин.

●

— Дәвалануы җиңел түгел икән, агайнеләр,— дип сөйли Сәләхи курорттан кайткач үзенең ахириләренә.— Ике атна буена су эчертеп дәвалаган булдылар.

— Ә эчкәч кабарга нәрсә бирәләр иде соң!

●

— Миңа ничә яшь бирер идегез!

— Әйтә алмыйм, ханым. Әмма бер нәрсәне төгәл беләм: үзегез теләгән яшьтә сез...

●

Аптекада.

— Миңа нинди дә булса йоклаткыч дару бирегезче. Әмма бик көчлесе булмасын.

— Менә монысын алыгыз. Бөтенләй йоклатмый торганын...

●

— Гаепләнүче, сез алтын сәгать урлауда гаепләнәсез.

— Бу икеләтә ялган! Беренчедән, мин бер нәрсә дә урламадым, икенчедән, сәгате алтын түгел икән бит, каһәрнең!

●

Карт диңгезче оныгына:

— Бервакыт Бермуд өчпочмагының нәкъ үзәгендә коточкыч зур дулкын безнең корабльне биш катлы йорт биеклегенә күтәрде дә аска томырды...— дип сөйли.— Командадан бер генә кеше дә исән калмады.

— Ә син, бабай, ничек исән калдың!

— Мин ул чакта күптән пенсиядә идем инде...

●

Аучыдан хатыны:

— Бу куянны үзең атып алдыңмы!— дип сорый.

— Үзем, билгеле! Зурлыгын күр син аның!

— Куян әйбәт. Тик нигә аның клеймәсе бар соң!

— Клеймәсен илле метрдан ничек күрмәк кирәк аның!!

●

Музейда экскурсовод:

— Монысы — фиргавеннең улы, бусы — хатыны, тегесе — энесе, ә бу — аның мумиясе,— дип аңлата.

— Гафу итегез,— дип сорый бер турист,— мумия дигәне фиргавеннең кеме була соң!

●

— Кызым, сиңа тагылып йөри торган егет миңа бөтенләй дә ошамый.

— Кайгырма, әнием, ул да сине җен урынына күрә!

Бу сандагы рәсем темаларын уйлап табучылар: А. Апешичев (Мәскәү), И. Анчуков (Воронеж), С. Веткин (Мәскәү), В. Игнатьев (Түбән Кама), В. Исаев (Пенза), И. Сопиков (Свердловск өлкәсе), И. Суровцев (Воронеж), Г. Тоцкий (Кустанай), С. Айнетдинов, Ф. Вахитов, В. Космылин һәм В. Феоктистов (Казан).

В. ФЕОКТИСТОВ рәсеме.



Т. ФӘИЗОВ рәсеме.



— Нигә уятмадың, нәгъләт!! Тагын йоклап калдыңмы!!

Бәясе 25 тиен.



№ 5 (1082)

Баш редактор Р. ЗӘКИЕВ.

Редколлегия: Б. БРОНШТЕЙН (баш редактор урынбасары), В. ИГНАТЬЕВ, Ә. ИСХАК, В. КОСМЫЛИН, В. ЛУЦЕНКО, Л. НАСЫЙРОВ, И. ХАНТИМЕРОВ, М. ХУҖИН (җаваплы секретарь).

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ НӘШРИЯТЫ
Журнал татарча һәм русча айга ике тапкыр чыга.

Художество редакторы Т. Фәизов. Техник редакторы М. Гатауллина.

Наборга бирелде 20.01.1984 ел. Басарга кул куелды 22.02.1984 ел. ПФ 08039. Кәгазь форматы 70×108¹/₈. Офсет ысулы белән басыла. Басма табагы 2,1. Учетн. изд. табагы 2,7. Тираж 585103. Заказ К-16.

КПССның Татарстан өлкә комитеты газета-журнал нәшрияты типографиясе. 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

© «Чаян», 1984 ел.

Редакциянең адресы:
420066, Казан,
Декабристлар урамы, 2,
«Чаян»

Телефоннар:

Баш редактор 53-20-76
Баш редактор урынбасары 53-57-85
Фельетоннар бүлеге мөдире 53-28-09
Җаваплы секретарь . . . 53-07-21
Фельетоннар бүлеге . . . 53-07-05
53-57-54
Баш рәссам 53-07-16
Әдәбият бүлеге 53-07-07
Хатлар бүлеге 53-57-67
Корректор 53-57-54

Журналга бәтен илдә чикләүсез язылырга мөмкин. Индекс 73488

СӘЕР КЕШЕЛӘР


Э. ДЫШАЕВ рәсеме.




И. АНЧУКОВ рәсеме.



В. ИСАЕВ рәсеме.



Ф. ВАХИТОВ рәсеме.



И. СУРОВЦЕВ рәсеме.



Г. ТОЦКИЙ рәсеме.



